СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 23, с.Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 23 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)3-92-40, факс (84366)3-92-40. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**
**Апаз авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

« 30 » март 2021ел № 25

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә гражданнарны сораштыру билгеләү һәм уздыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Советының 18.12.2020 ел, № 16 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Уставы нигезендә, Апаз авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру, шулай ук Апаз авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан карарлар кабул иткәндә халык фикерен ачыклау һәм аны исәпкә алу максатыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә гражданнарны сораштыру билгеләү һәм уздыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Советының 18.12.2020 ел, №16 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә гражданнарны сораштыру билгеләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә" түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге гражданнарын сораштыру түбәндәге инициатива белән үткәрелә:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Советы яисә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башлыгы инициативасы белән -җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча;

- Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы белән- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге җирләренең региональ һәм регионара әһәмияттәге объектлар өчен максатчан билгеләнешен үзгәртү мәсьәләләре буенча;

- инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган муниципаль берәмлектә яисә аның өлешендә уналты яшькә җиткән яшәүчеләр инициативасы белән - әлеге инициатив проектка ярдәм күрсәтү буенча гражданнарның фикерен ачыклау өчен.»;

1.2. 5.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Советына караган сораштыру үткәрү инициативасы күрсәтелгән орган тарафыннан сораштыру билгеләү турында тиешле карар кабул итүдә чагыла.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башлыгына караган сораштыру  уздыру инициативасы Җирлек Советына сораштыру үткәрү турында үтенечнамә юллауда чагыла.

Муниципаль берәмлек яисә аның өлеше халкына караган сораштыру үткәрү инициативасы инициатив төркем тарафыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Советына сораштыру үткәрү турында үтенечнамә юллауда чагыла;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Апаз авыл җирлеге башлыгы                                        Р.Ф.Котдусов

СОВЕТ АПАЗОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ОГРН 1021606156857
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АПАЗОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ИНН 1609003056